# СЫЙФАТ ТЕМАСЫН ГОМУМИЛӘШТЕРЕП ЙОМГАКЛАУ



# Максат:

1. *Белем ныклыгын сынау, эш ысулларын ныгыту, сыйфатның сөйләмдәге ролен ачыклау; җөмләдә сыйфатны табу күнекмәсен үстерү.*
2. *Иҗади фикерләргә, белемне башкалар белән уртаклашырга өйрәтү, күзәтү, хәтерләү, игътибар итү сәләтен үстерү.*
3. *Җаваплылык, дисциплина, активлык, үз-үзеңә бәя бирү, такт хисе тәрбияләү юнәлешендә эшләү.*

# Хәерле иртә



*Казан -матур шәһәр.Анда Сөембикә манарасы, Кол Шәриф мәчете, Кремль, спорт сарайлары бар. Шәһәр уртасында Кабан күле урнашкан.Казан яныннан Идел, Казансу елгалары ага. Без туган шәһәребезне бик яратабыз.*

*Казан- бик матур, гүзәл шәһәр. Анда горур Сөембикә манарасы, сокланггыч Кол Шәриф мәчете, ап-ак Кремль, мәһабәт спорт* сарайлары бар. Шәһәр уртасында тирән Кабан күле урнашкан.Казан яныннан мул сулы Идел, Казансу елгалары ага. Без туган шәһәребезне бик яратабыз.

# Матур язу күнегүләре

*Лл, Мм, Яя, Аа*

*Яшел, яшелрәк, ямь-яшел, яшькелт.*

# Төп дәрәҗә

***Предметның гадәттәге билгесен белдерә.***



***Кызыл алма***

# Чагыштыру дәрәҗәсе

*Бер предметтагы билгенең*
*башка предметтагы шундый ук билгедән артыграк булуын белдерә.*





*Кызылрак алма*

# Артыклык дәрәҗәсе

***Бер предметтагы билгенең шундый ук предметтагы билгедән бик күпкә артык икәнлеген белдерә.***

***Кып-кызыл алма***





# Кимлек дәрәҗәсе

*Предмет билгесенең гадәттәгедән ким, азрак булуын белдерә.*

***Кызгылт алма***





# Сыйфат дәрәҗәләре

| *төп* | *чагыштыру* | *артыклык* | *кимлек* |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

Кызыл алма

ап-ак кар

яшькелт яфрак

түгәрәк алан

бик матур чәчәк

биегрәк агач

салкынрак көн

зәңгәрсу күк йөзе



*Зәңгәр күктә болытлар йөзә.*

*Ап-ак кар ява.*

*Көн салкын.*

# Тест



# *Сыйфат моделен ясау*

**Дәрестәге активлыгыгыз, тырышлыгыгыз өчен бик зур рәхмәт! Укуыгызда зур уңышлар телим.**

